МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 гыйнвар 2017 ел. № 11 05

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җыелма эвакуация пунктларын төзү һәм аларның эшен оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 нче Карары, Татарстан Республикасы буенча ГТХМ Баш идарәсенең «Җыелма эвакуация пунктлары төзү һәм аларның эшен оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2011 елның 13 апрелендәге 236/159 нчы Боерыгы нигезендә, аерым чорда эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү һәм аларны тәэмин итү өчен

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җыелма эвакуация пунктларының (алга таба – ҖЭП) исемлеген, 1 нче кушымтада каралганча;

2) ҖЭП турында нигезнамәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә 2017 елның 1 февраленә кадәр, ана һәм бала бүлмәсен кирәкле мөлкәт белән комплектлаштыру өчен, һәр җыелма эвакуация пунктына мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен беркетергә.

3. Тәкъдим итәргә:

1) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә 2017 елның 1 февраленә кадәр, штат хезмәткәре булмаган очракта, медицина пунктын комплектлаштыру өчен һәр ҖЭПка медицина хезмәткәре беркетергә;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә:

- эвакуация чараларын үткәрү чорында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен шәһәрнең ҖЭП җитәкчелеге белән үзара эшчәнлекне оештырырга;

- бары тик махсус пропуск булганда һәм тулысынча эвакуацияләү игълан ителгән очракта, эвакуацияләүче автомобиль колонналарының шәһәр территориясеннән чыгуын тәэмин итәргә;

3) Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты бүлеге тарафыннан гражданнарны мобилизация буенча гарантияләнгән чакыруны үткәрү максатында, бер үк вакытта гражданнарны мобилизацияләү һәм эвакуацияләүне үткәрү шартларында, командаларга һәм партияләргә теркәлгән (билгеләнгән) гражданнарны мобилизация буенча чакыру өчен ачыклау буенча тикшерүне гамәлгә ашырырга;

4) шәһәр оешмалары җитәкчеләренә – ҖЭПны формалаштыручыларга 2017 елның 1 гыйнварына кадәр:

- формалаштырыла торган ҖЭП администрациясен билгеләүне тәэмин итәргә;

- ҖЭП эшен оештыру буенча кирәкле документларны эшләргә һәм Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсе белән килешенергә;

- ҖЭП төзү һәм аларның администрациясен билгеләү турындагы боерыкларның күчермәләрен Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсенә тапшырырга;

5) хезмәткәрләрен һәм аларның гаилә әгъзаларын шәхси транспорт белән эвакуацияләү һәм таратып урнаштыру планлаштырылган шәһәр оешмалары җитәкчеләренә, соңыннан чыгымнарны кире кайтару шарты белән, эвакуациягә бәйле йөртүләрне тәэмин итү өчен шәхси автотранспорт хуҗасы белән транспорт чараларыннан файдалану турында килешенү-йөкләмә төзергә;

6) Яр Чаллы шәһәренең идарә компанияләре җитәкчеләренә Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсе белән бергәләп кирәкле документларны эшләп, эшләмәүче халыкны эвакуацияләүне планлаштыруны оештырырга;

7) эвакуацияләүче автомобиль колонналарын формалаштыра торган шәһәр оешмалары җитәкчеләренә Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлеге белән берлектә, эвакуация чаралары барышында куркынычсыз районга тоткарлыксыз йөрү өчен пропусклар әзерләргә;

8) Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсенә шәһәрнең эвакуация комиссиясе белән берлектә, җыелма эвакуация пунктлары эшчәнлеген регламентлаштыра торган документларны эшкәртү эшен оештырырга.

4. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җыелма эвакуация пунктларын төзү һәм аларның эшен оештыру турында» 2015 елның 7 декабрендәге М 366 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2017 елның 12 гыйнварындагы
М 05 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең җыелма эвакуация пунктлары (ҖЭП)
исемлеге

| ҖЭП № | ҖЭП төзү урыны | ҖЭПны формалаштыручы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | АБК-407 «КАМАЗ» ААҖ Автомобиль заводы | «КАМАЗ» ААҖ Автомобиль заводы | |
| 2 | Яр Чаллы шәһәренең «56 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Нариманов урамы, 44 (62/24) | Яр Чаллы шәһәренең «56 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 3 | «46 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Чулман проспекты, 56 (42/18) | «КАМАЗ» ААҖ Коюю заводы | |
| 4 | АБК-6 «КАМАЗ» ААҖ Коюю заводы | «КАМАЗ» ААҖ Коюю заводы | |
| 5 | Яр Чаллы шәһәренең «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Ш.Усманов урамы, 96 (47/18) | «КАМАЗ» ААҖ Ремонт-инструмент заводы | |
| 6 | АБК-211 «КАМАЗ» ААҖ Тимерчелек заводы | «КАМАЗ» ААҖ Тимерчелек заводы | |
| 7 | «Орган залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе, Автозавод проспекты, 8 (25/05) | «КАМАЗ» ААҖ АХО департаменты | |
| 8 | «КАМАЗ» МС» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе, Тынычлык проспекты, 87/22 | «КАМАЗ» ААҖ Двигательләр заводы | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | АБК-306(1)<br>«КАМАЗ» ААҖ<br>Двигательләр заводы | «КАМАЗ» ААҖ<br>Двигательләр заводы | |
| 10 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Тынычлык проспекты, 29 (11/08) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 11 | АБК-408(1)<br>«КАМАЗ» ААҖ<br>Автомобиль заводы | «КАМАЗ» ААҖ<br>Автомобиль заводы | |
| 12 | Яр Чаллы шәһәренең<br>«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе,<br>Школьный бульвары, 2 (18/09) | «КАМАЗ» ААҖ<br>Пресс-рам заводы | |
| 13 | АБК-107<br>«КАМАЗ» ААҖ<br>Пресс-рам заводы | «КАМАЗ» ААҖ<br>Пресс-рам заводы | |
| 14 | Яр Чаллы шәһәренең<br>«38 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Чулман проспекты, 78 (44/08) | «КАМАЗ» ҖЧҖ<br>Логистика үзәге | |
| 15 | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе,<br>Сөембикә проспекты, 47 (43/20) | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе | |
| 16 | Яр Чаллы шәһәренең<br>«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 24 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Автозавод проспекты, 39 (20/08) | «КАМАЗ-Энерго» ҖЧҖ | |
| 17 | «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яшь Ленинчылар бульвары, 7 (27/22) | «Электротранспорт» ҖЧҖ | |
| 18 | «Генерацияләүче компания» ААҖ филиалы – «Яр Чаллы жылылык челтәрләре»,<br>Шишкин бульвары, 1 (30/23) | «Генерацияләүче компания» ААҖ филиалы – «Яр Чаллы жылылык челтәрләре» | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19 | Яр Чаллы шәһәренең «48 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Вахитов проспекты, 3 (54/23) | «КАМАЗ» ААҖ Ремонт-инструмент заводы | |
| 20 | «Региональ алдынгы технологияләр һәм бизнес институты» дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениесе, Вахитов проспекты, 2 (53/03) | «Ремдизель» АҖ | |
| 21 | АБК-7, «Мастер» КИП АҖ, Производственный тыкрыгы, 45 | «КАМАЗ» ААҖ Запас частьлар һәм компонентлар заводы | |
| 22 | Блок 1 «КАМАЗ» ААҖ генераль директоры урынбасары – үсеш буенча директор блогы | «КАМАЗ» ААҖ генераль директоры урынбасары – үсеш буенча директор блогы | |
| 23 | «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ Кунакханә комплексы, Рубаненко бульвары, 4 (1/06) | «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ | |
| 24 | «Бизнесцентрпремьер» ҖЧҖ («Батыр» күңел ачу комплексы»), Х. Туфан проспекты, 14, (3/02) | «Чаллы-Суык» АҖ | |
| 25 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮһББ ФДАМУ Яр Чаллы институты, Тынычлык проспекты, 13 а | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮһББ ФДАМУ Яр Чаллы институты | |
| 26 | АБК-407 (2) «КАМАЗ» ААҖ Автомобиль заводы | «КАМАЗ» ААҖ Автомобиль заводы | |
| 27 | «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре, Мәскәү проспекты, 54/24 йорт | «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре | |
| 28 | «Форд – СОЛЛЕРС Холдинг» ҖЧҖ, Автосборочный тыкрыгы, 60 | «Форд – СОЛЛЕРС Холдинг» ҖЧҖ | |
| 29 | «Яр Чаллы педагогия колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе, Беляев проспекты, 3 (56/04) | «ПЖДТ-Сервис» ҖЧҖ | |
| 30 | «23 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Ш.Усманов урамы, 82 (47/09) | «23 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 31 | «Генерациялəүче компания» ААЖ филиалы – Яр Чаллы ТЭЦ, Тэцовский тыкрыгы, 76 | «Генерациялəүче компания» ААЖ филиалы – Яр Чаллы ТЭЦ | |
| 32 | «КамгэсЗЯБ» ҖЧҖ, Яр Чаллы проспекты, 39 | «КамгэсЗЯБ» ҖЧҖ | |
| 33 | Яр Чаллы шəһəренең «Дельфин» балалар-яшүсмерлəр спорт мəктəбе» муниципаль автономияле өстəмə белем бирү учреждениесе, Габдулла Тукай Яр буе урамы, 12 | Яр Чаллы шəһəренең «Дельфин» балалар-яшүсмерлəр спорт мəктəбе» муниципаль автономияле өстəмə белем бирү учреждениесе | |
| 34 | «Калкан» полиция кадетлар мəктəбе» дəүлəт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Маршал Жуков урамы, 36 | «Бумажник» ТИ» БҖЧҖ | |
| 35 | «Мулланур Вахитов исемендəге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Ак. Королев урамы, 20 (32/20) | «Мулланур Вахитов исемендəге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 36 | «25 нче урта гомуми белем бирү мəктəбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Тынычлык проспекты, 54 (3/13) | «25 нче урта гомуми белем бирү мəктəбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 37 | Яр Чаллы шəһəренең «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Чулман проспекты, 72 (42/25) | Яр Чаллы шəһəренең «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 38 | Яр Чаллы шəһəренең «61 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Романтиклар бульвары, 2 (54/09) | Яр Чаллы шəһəренең «61 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 39 | «29 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Яшь Ленинчылар бульвары, 3 (27/21) | «Челныстройремонт» идарə компаниясе ҖЧҖ | |
| 40 | «3 нче урта гомуми белем бирү мəктəбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Юность тыкрыгы, 1 (6/16) | «3 нче урта гомуми белем бирү мəктəбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 41 | «9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Грин урамы, 8/2 | «Просто молоко» ИК ААҖ филиалы – «Яр Чаллы сөт комбинаты» | |
| 42 | АБК<br>Автобаза №48, БСИ | «Трест Камдорстрой» ЯАҖ | |
| 43 | «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе,<br>Ш.Усманов урамы, 5 (32/04) | «Строим будущее» ИК ҖЧҖ | |
| 44 | Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе,<br>Тукай Яр буе урамы, 16 | «Чаллы икмәге» АҖ | |
| 45 | «7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Комаров урамы, 29 (17/28) | «7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 46 | «Энергетик» МС» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе,<br>Тукай Яр буе, 31 | «Яр Чаллы сәнгать колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе | |
| 47 | «5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Энергетиклар тыкрыгы, 1 (5/16) | «Домкор индустрия» ҖЧҖ | |
| 48 | «СИЛИКАТ КИРПЕЧ ЗАВОДЫ» ҖЧҖ,<br>Яр Чаллы проспекты, 37 | «СИЛИКАТ КИРПЕЧ ЗАВОДЫ» ҖЧҖ | |
| 49 | Яр Чаллы шәһәренең «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Тинчурин бульвары, 2 (10/50) | Яр Чаллы шәһәренең «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 50 | Яр Чаллы шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе,<br>Батенчук урамы, 17 | Яр Чаллы шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе | |
| 51 | «Строй-Кран» ҖЧҖ<br>Махсуслаштырылган Үзәк,<br>Минзәлә тракты, 136/2 | «Строй-Кран» ҖЧҖ<br>Махсуслаштырылган Үзәк | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 52 | Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» 1 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, М. Җәлил проспекты, 31 йорт | «Жилкомсервис» ЖКФ ҖЧЖ | |
| 53 | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе, Казан проспекты, 17 | «Ак Барс Металл» ҖЧЖ | |
| 54 | «Р.О.С.Л.А.» ҖЧЖ БСИ, Цеховой тыкрыгы, 8 | «Р.О.С.Л.А.» ҖЧЖ | |
| 55 | Яр Чаллы шәһәренең «Урман иясе» 88 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Саначин Яр буе урамы, 16 (17а/16) | «С.П. Титов исемендәге Яр Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» эЯАҖ | |
| 56 | Яр Чаллы шәһәренең «64 нче прогимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, М. Җәлил проспекты, 37 | «Электр челтәрләре предприятиесе» ҖЧЖ | |
| 57 | «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Гидротөзүчеләр бульвары, 5 (2/15) | «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 58 | «11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Шамил Усманов урамы, 10, (32/13) | «Электротехник» идарә компаниясе ҖЧЖ | |
| 59 | Яр Чаллы шәһәренең «Г.Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Мәскәү проспекты, 100 (56/07) | Яр Чаллы шәһәренең «Г.Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 60 | Яр Чаллы шәһәренең «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Ш. Усманов урамы, 110 (49/04) | «Камстройсервис» ТФИ ҖЧЖ | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 61 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 37 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Сөембикә проспекты, 103 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 37 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 62 | «Домкор Строй» ҖЧҖ, БСИ, Старосармановская урамы, 21 | «Домкор Строй» ҖЧҖ | |
| 63 | Яр Чаллы шәһәренең «17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Р.Беляев проспекты, 26 (16/05) | Яр Чаллы шәһәренең «17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 64 | Яр Чаллы шәһәренең «4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Һ. Такташ урамы, 35 (18/13) | Яр Чаллы шәһәренең «4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 65 | «РБР-16» ҖЧҖ, Магистральная урамы, 12 | «РБР-16» ҖЧҖ | |
| 66 | «8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Һ. Такташ урамы,36/7 | «8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 67 | Яр Чаллы шәһәренең «А.С. Пушкин исемендәге 78 нче лицей» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Шишкин бульвары, 11 (42/20) | «Паритет» ИК ҖЧҖ | |
| 68 | «60 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Р.Беляев проспекты, 60 (13/12) | «60 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 69 | «22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Солнечный бульвары,2 (17/18) | «Ремжилстрой» ИК ҖЧҖ | |
| 70 | «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Һ. Такташа урамы, 27 (18/15) | «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 71 | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 29 (56/30) | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 72 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 50 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Ш.Усманов урамы, 19 (31/13) | «Мәхәллә» ИК ЖЧЖ | |
| 73 | «Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» югары һөнәри белем бирү дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе, Мәскәү проспекты, 95 (8/02) | «Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» югары һөнәри белем бирү дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе | |
| 74 | Яр Чаллы шәһәренең «57 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Халыклар Дуслыгы проспекты, 9а (58/17) | «Булгарпиво» ААЖ | |
| 75 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Бумажник бульвары, 3 (17а\18) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 76 | «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, С. Сәйдашев урамы, 10 (9/56) | «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 77 | Яр Чаллы шәһәренең «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Тимерьюлчылар урамы, 65 (15/23) | Яр Чаллы шәһәренең «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 78 | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» ЮҺББ ФДБМУ Яр Чаллы колледжы (филиалы), Батенчук урамы, 21 (3/16) | Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» ЮҺББ ФДБМУ Яр Чаллы колледжы (филиалы) | |
| 79 | «Бизнес һәм менеджмент урта гомуми белем бирү мәктәбе» шәхси гомуми белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы проспекты, 53 (32/16) | «Бизнес һәм менеджмент урта гомуми белем бирү мәктәбе» шәхси гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 80 | Яр Чаллы шәһәренең «51 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Автомобилестроители бульвары, 9 (52/37) | Яр Чаллы шәһәренең «51 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 81 | «12 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Корчагин бульвары, 2 (10/16) | «12 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 82 | «52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Автомобилестроители бульвары, 5 (52/36) | «52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 83 | «58 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Кол Гали бульвары, 22 (58/09) | «58 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 84 | Яр Чаллы шәһәренең «49 нчы кадетлар мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, Чулман проспекты, 136 (50/16) | Яр Чаллы шәһәренең «49 нчы кадетлар мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 85 | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе, М.Җәлил проспекты, 10 | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе | |
| 86 | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе, М Җәлил проспекты, 14 | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе | |
| 87 | «Кама икътисад-хокук колледжы» шәхси һөнәри гомуми белем бирү учреждениесе, Касыймов бульвары, 3 (39/17) | «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ | |
| 88 | «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, Грин урамы, 9 | «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе | |
| 89 | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама политехника колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе, М Җәлил проспекты, 6 | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама политехника колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе | |
| 90 | «Яр Чаллы политехника колледжы» дәүләт автономияле һөнәри гомуми белем бирү учреждениесе, Р.Беляев проспекты, 5 | «Яр Чаллы политехника колледжы» дәүләт автономияле һөнәри гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 91 | «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Главмосстроевцы бульвары, 2 (18/18) | 26 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 92 | Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе, Сөембикә проспекты, 44 | Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе | |
| 93 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 19 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Шишкин бульвары, 9 (30/20) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 19 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 94 | «79 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Татарстан урамы, 27 (48/19) | «79 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 95 | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Чулман проспекты, 38 (40/14) | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 96 | «54 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Касыймов бульвары, 6 (38/06) | «54 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 97 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 18 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Төзүчеләр бульвары, 1 (5/10) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 18 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 98 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Чулман проспекты, 34 (40/12) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 99 | «53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Касыймов бульвары, 23 (38/10) | «53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 100 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Чәчәкле бульвары, 15 (23/08) | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 101 | «33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Татарстан урамы, 14 (25/22) | «33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 102 | Яр Чаллы шәһәренең<br>«15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Шишкин бульвары, 26 (29/23) | Яр Чаллы шәһәренең<br>«15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 103 | Яр Чаллы шәһәренең<br>«55 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Ш. Усманов урамы, 128А (51/15) | «Чаллы су каналы» АҖ | |
| 104 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең<br>Яр Чаллы институты (филиалы),<br>Тынычлык проспекты, 68/19 (1/18) | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең<br>Яр Чаллы институты (филиалы) | |
| 105 | «30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Илдар Маннанов урамы, 12 (37/19) | «30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2017 елның 12 гыйнварындагы
М 05 нче карарына
2 нче кушымта

Җыелма эвакуация пункты турында нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 нче Карары нигезендә, җыелма эвакуация пунктлары (алга таба – ҖЭП) эвакуацияләнә торган халыкны җыю, исәбен алу һәм оешкан төстә аларны куркынычсыз районга озату өчен төзелә. ҖЭП җәмәгать билгеләнешендәге биналарда, транспортка утырту пунктларына якын урында урнаша.

2. ҖЭП шәһәрнең эвакуация комиссиясе, арадаш эвакуация пункты администрацияләре, куркынычсыз районнарда урнашкан эвакуация-кабул итү комиссияләре, шулай ук эвакуация чараларын үткәрү өчен транспорт белән тәэмин итүче оешмалар элемтәсе белән тәэмин ителә. ҖЭПка эшләмәүче гаилә әгъзалары булган хезмәткәрләрнең оешмалары һәм производствода эшләмәүче башка халык беркетелә һәм алар әлеге җыелма эвакуация пункты аша эвакуацияләнә.

3. ҖЭПка беркетелә:

1) якындагы саклагыч гражданнар оборонасы корылмалары яки биналарның ышыклану урыны буларак файдаланылырга мөмкин булган подвал бүлмәләре;

2) медицина учреждениеләре;

3) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре;

4) хокук саклау органнары;

5) транспорт белән тәэмин итүче оешмалар.

ҖЭП шәһәр Хакиме карары белән төзелә.

4. ҖЭП исемлеге шәһәр Хакиме карары белән раслана.

5. Халыкны ҖЭПка теркәү бер пунктка 4000-5000 кеше исәбеннән чыгып башкарыла. ҖЭПка бирелә торган транспорт чараларының саны теркәлгән халык санына, билгеләнгән срокта халыкны чыгаруны тәэмин итә торган автоколонна рейслары санына туры китереп билгеләнә. ҖЭП аша эвакуация чаралары производство-территориаль принцип буенча планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла, аның нигезендә эшчеләрне, хезмәткәрләрне һәм аларның гаиләләренең эшләмәүче әгъзаларын тарату һәм эвакуацияләү – оешмаларда, ә башка халыкны эвакуацияләү территориаль принцип буенча торак-файдалану органнары аша яшәү урыны буенча оештырыла һәм башкарыла. ҖЭП төзү гражданнар оборонасының

гомуми әзерлек чаралары үтәлгәндә яки гомуми эвакуацияләүне үткәрүгә турыдан-туры боерык алганда башкарыла.

6. ҖЭПның эвакуацияләнә торган халыкны үз вакытында җыю һәм озатуны тәэмин итү буенча эше тәүлек буе оештырыла. ҖЭП администрациясе, базасында ҖЭП төзелә торган оешмаларның, шулай ук үз кешеләрен аның аша эвакуацияли торган оешмаларның хезмәткәрләре арасыннан билгеләнә.

7. ҖЭП башлыгы шәһәрнең эвакуация комиссиясе рәисенә, шулай ук гражданнар оборонасы җитәкчесенә һәм базасында ҖЭП төзелгән оешманың эвакуация комиссиясе рәисенә буйсына. ҖЭП башлыгы тыныч чорда алдан ук Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәгенең Яр Чаллы шәһәрендәге филиалында әзерлек уза. ҖЭП хезмәткәрләре әзерлекне эш урынында, шулай ук гражданнар оборонасы буенча уку һәм тренировкаларда узалар.

8. ҖЭП администрациясе үзенең функциональ вазыйфаларын үтәүгә табигый һәм техноген характердагы эре масштаблы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы янаганда (барлыкка килгәндә) җәлеп ителә. ҖЭП эшенә әзерлек, ҖЭП составына кергән хезмәткәрләрне әзерләү, аны кирәкле материаль-техник мөлкәт белән җиһазландыру өчен җаваплылык ҖЭП эшен формалаштыра һәм тәэмин итә торган оешмаларның җитәкчеләренә йөкләнә.

9. ҖЭПның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) шәһәрнең эвакуация комиссиясе, ҖЭПка беркетелгән оешмалар, ҖЭПны транспорт белән тәэмин итүгә җаваплы транспорт оешмалары, арадаш эвакуация пунктлары һәм ҖЭП аша халык эвакуацияләнә торган муниципаль районнарның кабул итүче эвакуация комиссияләре белән элемтәдә тору;

2) ҖЭПка беркетелгән оешмаларга һәм халыкка ҖЭПка килү вакыты турында үз вакытында хәбәр итү;

3) эвакуацияләнә торган халыкны куркынычсыз районга озату өчен транспорт чараларын үз вакытында бирүне котрольдә тоту;

4) барлык төр транспортта эвакуацияләнә торган халык исәбен алып бару;

5) эвакуацияләнә торган халыкны транспортка утыртуны оештыру һәм аларны куркынычсыз районга озату;

6) ҖЭПта булу чорында авыруларга кирәкле медицина ярдәме күрсәтү;

7) радиация һәм химик күзәтү алып бару;

8) халык тарафыннан җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

9) гражданнар оборонасы сигналлары буенча эвакуацияләнә торган халыкның саклагыч корылмаларда ышыклануын оештыру.

## 2 бүлек. ҖЭП структурасы:

10. ҖЭП түбәндәге структурага ия:

Идарә

| | |
|---|---|
| ҖЭП башлыгы | - 1 кеше |
| ҖЭП башлыгы урынбасары | - 1 кеше |
| Комендант | - 1 кеше |
| **Хәбәр итү һәм элемтә төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Оператор-телефонист (саны хәбәр итела торган оешмалар санышнан чыгып билгеләнә) | - 3-6 кеше |
| **Теркәү һәм исәпкә алу төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе – өлкән хисапчы | - 1 кеше |
| Хисапчылар (саны ҖЭП йөкләмәсеннән чыгып билгеләнә) | - 3-6 кеше |
| **Колонналарны формалаштыру (комплектлаштыру) төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1 кеше |
| Формалаштыручы (саны ҖЭП йөкләмәсеннән чыгып билгеләнә) | - 4-8 кеше |
| Һәр ҖЭПның колонналарны формалаштыру төркеме составына автоколонналар буенча җаваплы зат кертелә. | |
| **Транспорт белән тәэмин итү төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1-2 кеше |
| **Ышыклану урыны төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1-3 кеше |
| **Җәмәгать тәртибен саклау төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Патруль (саны ҖЭП йөкләмәсеннән чыгып билгеләнә) | - 1-4 кеше |
| Тәртип саклау посты (ЭЭМ хезмәткәрләре) | - 2 кеше |
| **Медицина пункты** | |
| Пункт башлыгы – фельдшер | - 1 кеше |
| Шәфкать туташы | - 1 кеше |
| Санитар машинасын йөртүче | - 1 кеше |
| **Ана һәм бала бүлмәсе** | |
| Бүлмә мөдире | - 1 кеше |
| Тәрбияче | - 1-3 кеше |
| **РХН посты** | |
| Пост башлыгы | - 1 кеше |
| Дозиметрист | - 1 кеше |
| **Белешмәләр өстәле** | |
| Өстәл башлыгы | - 1 кеше |
| Ярдәмче | - 1 кеше |

ҖЭПта барлыгы – 35 - 53 кеше.

11. ЖЭПта, эшләмәүче халыкка индивидуаль саклану чаралары бирү өчен, 29 кешегә исәпләнгән индивидуаль саклану чаралары бирү пункты ачыла.

## 3 бүлек. Җыелма эвакуация пункты эшен оештыру тәртибе

12. Гражданнар оборонасы буенча беренче чираттагы өченче чират чараларын үткәрүгә боерык алынганнан соң территориаль, тармак һәм объект эвакуация органнары урнаштырыла һәм әзерләнә. 1-2 сәгать эчендә ЖЭП администрациясе җыела. Эвакуация чараларын үткәрүгә боерыкны алганнан соң 3-4 сәгать эчендә ЖЭП урнаштырыла һәм эшкә әзер була.

13. ЖЭП төзелгәннән соң ЖЭП башлыгы түбәндәгеләрне оештыра:

- штат-вазыйфа исемлеге нигезендә ЖЭПның шәхси составын тикшерү;
- эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләренең җәмәгать тәртибен саклау төркеменә килүе;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең ана һәм бала бүлмәсенә килүе;
- медицина учреждениеләре хезмәткәрләренең ЖЭПның медицина пунктына килүе;
- автомобиль колоннасы килүне аныклау;
- тимер юл станциясенә поезд бирелү;
- ЖЭПка теркәлгән оешмалар житәкчелеге белән эвакуацияләнергә тиешле халык санын, аларны куркынычсыз районнарга озату тәртибен һәм срокларын аныклауны;
- ЖЭПка теркәлгән барлык төр транспорт белән эвакуацияләнә торган халыкны чыгаруга исәп-хисапларны аныклауны;
- эвакуацияләнә торган халыкка индивидуаль саклану чаралары бирү чараларын гамәлгә ашыру;
- ЖЭПка килүче эвакуацияләнә торган халыкны теркәү һәм исәбен алу;
- колонналарны һәм эвакуация эшелоннарын формалаштыру;
- эвакуацияләнүче халыкны транспорт чараларына утырту;
- ЖЭПтагы барлык төркемнәренең эше;
- колонналарның җаваплы затларына инструктаж үткәрү;
- ЖЭПта булу вакытында авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү;
- җәмәгать тәртибен саклауны һәм гражданнар оборонасы сигналлары буенча эвакуацияләнүче халыкны ышыкландыру;
- эвакуация чаралары тәмамланганнан соң, шәһәрнең эвакуация комиссиясенең боерыгы буенча шәһәрнең эвакуация комиссиясенә халыкны шәһәрдән читтәге зонага озату турында доклад әзерләү;
- ЖЭПның шәхси составын эвакуацияләү.

14. ЖЭП администрациясе оешмаларның эвакуация комиссияләре вәкилләре белән берлектә, эвакуацияләнә торган халык килгән саен, аларны кабул итүне, теркәүне, бүлүне, автомашиналар буенча җаваплы затларны билгеләүне һәм билгеләнгән вакытта формалаштыручылар ярдәме белән оешмаларның утырту пунктына чыгуын оештыра.

15. ЖЭПка (пунктлар, утырту урыннары) автоколонналар бирү вакыты эвакуация чаралары үткәрүгә боерык алынганнан соң 4 сәгатьтән дә соң булмаган вакытка билгеләнә (Ч + 4.00).

16. Беренче колонналар белән озатыла торган оешмаларга хәбәр итү, оешмалар Ч +4 сәгатьтән дә соңга калмый ЖЭПка килеп житү исәбе белән башкарыла. Аннан соң ЖЭПка теркәлгән оешмаларга хәбәр итү чираттагы автомобильләр колоннасы китү вакытына кадәр 5-6 сәгать алдан гамәлгә ашырыла. Эвакуацияләнүчеләр колонналар киткәнче кимендә 1 сәгать алдан килергә тиеш.

17. Һәр колоннаны озатканнан соң, ЖЭП башлыгы кирәкле мәгълүматларны шәһәрнең эвакуация комиссиясенә тапшыра.

18. Транспорт бирү тоткарланган очракта, ЖЭП башлыгы шәһәрнең эвакуация комиссиясенә транспортның тоткарлану сәбәбе турында хәбәр итә, шулай ук, ЖЭПта һәм утырту урыннарында халыкның күпләп җыелуын булдырмау максатында, әлеге транспортка теркәлгән оешмаларны кисәтә.

19. ЖЭПта җәмәгать тәртибен тәэмин итүне җәмәгать тәртибен саклау төркеме белән берлектә комендант оештыра.

20. Эвакуация чараларын үткәрү чорында эвакуацияләнүче халыкка медицина ярдәме күрсәтү чаралары ЖЭПта, утырту урыннарында, эвакуация маршрутларында, шулай ук шәһәрдән читтәге зоналарда төшерү һәм урнашу районнарында оештырыла. Әлеге максат өчен медицина хезмәткәрләре, гражданнар оборонасы чараларын медицина буенча тәэмин итү планы нигезендә, шәһәрнең дәвалау учреждениеләреннән бирелә. ЖЭПта урнаштырыла торган медицина пункты составына бер фельдшер һәм 1-2 шәфкать туташы кертелә. Медпунктның бурычы – ЖЭПтагы халыкка табибка кадәр медицина ярдәме күрсәтү.

21. Барлык эвакуацияләнүчеләр өчен гомуми эвакуация исемлекләре төзелә. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр гаиләсенең эшләмәүче әгъзалары – гаилә башлыгының эш урыны буенча оешмаларда, ялгыз эшләмәүчеләр яшәү урыны буенча (торак-файдалану органнарында) исемлекләргә кертелә.

22. Мәктәп-интернат (яшәү) укучылары, балалар йортларында тәрбияләнүчеләр, шулай ук картлар һәм инвалидлар йортларында яшәүче пенсионерлар үз учреждениеләре һәм оешмалары составында эвакуацияләнә.

23. Мобилизация буенча Кораллы Көчләргә чакырылучы, шулай ук хәрби хезмәт үтүче эшчеләр һәм хезмәткәрләр гаиләләренең эшләмәүче әгъзалары әлек гаилә башлыгы эшләгән оешмалар белән бергә эвакуацияләнә.

24. Эвакуация исемлекләре алдан ук 3 нөсхәдә төзелә һәм периодик рәвештә эвакуация планнарына төзәтмә керткәндә, шулай ук гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә аныклана.

25. Эвакуация үткәрүгә боерыкны алгач, исемлекләрнең беренче нөсхәсе оешмада кала, икенчесе ЖЭПка җибәрелә һәм халыкны чыгарып бетергәннән соң эвакуация комиссиясенә тапшырыла; өченчесе теркәгәннән һәм урнаштырганнан соң эвакуацияләнүче халыкны кабул итә торган кабул итүче эвакуация пункты аша урнаштырыла торган районда эвакуация-кабул итү комиссиясенә җибәрелә.

26. Эвакуация исемлекләре һәм паспортлар эвакуацияләнә торган халыкны исәпкә алу, урнаштыру һәм беренче чиратта яшәешен тәэмин итү өчен төп документлар булып тора.

27. Эвакуацияләнә торган халыкны утырту урынына турыдан-туры килү түбәндәгеләргә рөхсәт ителә:

1) инвалидлар һәм картлар йортларында яшәүче гражданнар, мәктәп-интернат укучылары, балалар йортларында тәрбияләнүчеләр, хезмәт күрсәтүче персоналы һәм аларның гаилә әгъзалары булган махсус балалар учреждениеләре;

2) һөнәри белем бирү оешмалары һәм профессор-укытучы һәм хезмәт күрсәтүче персоналы һәм аларның гаилә әгъзалары булган югары һөнәри белем бирү оешмалары студентлары.

28. Әлеге оешмаларның эвакуация комиссиясе вәкилләре ҖЭПка килергә, үз оешмаларын теркәргә, эвакуацияләнүчеләр өчен тиешле документларны тапшырырга, автоколонналар буенча бүленеш мәгълүматларын алырга һәм шуннан соң гына кешеләрне транспортка утыртырга алып барырга тиеш.

29. Эвакуация чараларын үткәрү чорында шәһәр транспортының тәүлек дәвамында эшләве оештырыла.

30. ҖЭП эшен оештыру өчен төп озату документы булып оешма җитәкчесенең ҖЭП администрациясен билгеләү турында боерыгы һәм әлеге ҖЭП өчен халыкны һәм матди кыйммәтләрне эвакуацияләү планыннан өземтә тора.

## 4 бүлек. Эшләмәүче халыкны эвакуацияләүне оештыру үзенчәлекләре

31. Эшләмәүче халыкны һәм ялгыз пенсионерларны эвакуацияләү территориаль принцип буенча, ягъни яшәү урыны буенча башкарыла һәм идарә компанияләренә йөкләнә. Аларда исәпкә алу оештырыла, эвакуация планына төзәтмәләр керткәндә, шулай ук гражданнар оборонасын сугыш вакытына күчергәндә һәм эвакуацияләүгә боерык алганда, елына кимендә ике тапкыр ачыклана торган исемлекләр төзелә. Исемлекләрне ачыклау Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе һәм «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе аша башкарыла.

32. Эшләмәүче халыкны гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклану өлкәсендә өйрәтү, идарә компанияләре карамагында урнашкан укыту-консультация пунктларында оештырыла. Дәресләргә йөрү, эшләмәүче халыкның адресларын һәм телефоннарын күрсәтеп, дәресләр һәм консультацияләр исәбен алып бару журналларында теркәлә.

33. Барлык идарә компанияләрендә эшләмәүче халык өчен җитәрлек санда белешмәлек бланклары әзерләнергә тиеш. Алар гражданнар оборонасы чараларын (I чираттагы чаралар, II чираттагы чаралар, III чираттагы чаралар) үткәрүгә боерык алганнан соң өләшенә. Ә гомуми эвакуация игълан ителгәндә сигнал идарә компанияләренең үзәк диспетчерлык хезмәтләренә килә, аннан

соң 30 минут эчендә тәүлекнең теләсә кайсы вакытында барлык йорт идарәләренә хәбәр җибәрелә. Сигнал килгәннән соң тиз арада йорт идарәләренең техникларына (мастерларына), йорт һәм подъездлар буенча җаваплы затларга хәбәр җибәрелә. Алар эшләмәүче халыкны һәм пенсионерларны җыюны һәм озатуга әзерләне гамәлгә ашыралар. Халыкны һәм матди кыйммәтләрне эвакуацияләү планы нигезендә, һәр йорт идарәсе җыелма эвакуация пунктына беркетелә.

34. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, ялгыз пенсионерларны һәм эшләмәүче халыкны эвакуацияләү очрагы өчен, шәһәрнең торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиеләренә хәбәр итү схемасын эшли, әлеге схема Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсе белән килешенә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары — Ф.И. Андреева